КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 18 октябрь г.Казань № 944

Татарстан Республикасының дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең төрен үзгәртү юлы белән Татарстан Республикасында халыкка социаль хезмәт крсәтү өлкәсендә дәүләт казна учреждениеләрен (акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортларын) төзү турында

«Коммерциячел булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 1 гыйнварыннан түбәндәге дәүләт казна учреждениеләрен төзергә:

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» (алга таба – «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» ДКУ);

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе төрен үзгәртү юлы белән «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» (алга таба – «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» ДКУ).

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләрен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

гамәлгә ашыра;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләре максатлары булып социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип гражданнарның тереклек эшчәнлеге шартларын яхшырту һәм (яки) аларның үзләренең төп тереклек ихтыяҗларын мөстәкыйль рәвештә тәэмин итә алуны киңәйтү тора;

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» ДКУ койка фонды 80 стационар койка-урын, «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» ДКУ койка фонды 210 стационар койка-урын тәшкил итә;

«Акыл үсеше артта калган балалар өчен Югары Отар балалар интернат йорты» ДКУ хезмәткәрләренең чик штат саны 107,58 штат берәмлеге, «Акыл үсеше артта калган балалар өчен Дербышка балалар интернат йорты» ДКУнең 251,15 штат берәмлеге тәшкил итә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына 90 көн эчендә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре (акыл үсеше артта калган балалар өчен балалар интернат йортлары) уставларындагы тиешле үзгәрешләрне расларга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасының дәүләт казна учреждениеләре эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы, 1002 «Халыкка социаль хезмәт күрсәтү» бүлекчәсе буенча бюджет сметалары нигезендә каралган акча исәбеннән гамәлгә ашырыла.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин